КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 апрель г.Казань № 295

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын 2020 елда гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа коронавирус йогышы авыруы белән бәйле авырулар таралу куркынычы барлыкка килү шартларында 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы 2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Яңа коронавирус йогышлы авыруы белән бәйле авырулар таралу куркынычы барлыкка килү шартларында мәҗбүри медицина иминиятенең база программасын гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2020 ел, 3 апрель, 432 нче карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 ел, 21 март, 710-б номерлы боерыгының 2 пунктында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин